МИНИСТЕРСТВО
ТРУДА, ЗАНЯТОСТИ И
СОЦИАЛЬНОЙ ЗАЩИТЫ
РЕСПУБЛИКИ
ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ХЕЗМӘТ, ХАЛЫКНЫ ЭШ
БЕЛӘН ТӘЭМИН ИТҮ ҺӘМ
СОЦИАЛЬ ЯКЛАУ
МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

10.02.2020 г.Казань № 84

Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгында 2020 елның 12 мартында 6555 номеры белән теркәлде

Халыкка социаль ярдәм күрсәтү өлкәсендә дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең аерым административ регламентларына үзгәрешләр кертү турында

Халыкка социаль ярдәм күрсәтү өлкәсендә дәүләт хезмәтләрен күрсәтү эшен камилләштерү максатларында б о е р ы к б и р ә м:

1. Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының халыкка социаль ярдәм өлкәсендә дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең аерым административ регламентларына кертелә торган, кушымтада бирелгән үзгәрешләрне расларга.

2. Әлеге боерык рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Министр Э.Ә. Зарипова

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 10.02.2020 № 84 боерыгы белән расланды

Халыкка социаль ярдәм күрсәтү өлкәсендә дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең аерым административ регламентларына кертелә торган үзгәрешләр

1. Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Чернобыль АЭСында һәлакәт, 1957 елда «Маяк» җитештерү берләшмәсендә авария һәм Тичә елгасына радиоактив калдыклар элгү аркасында радиактив пычрануның аерым зоналары территориясеннән эвакуацияләнгән күчерелгән (кучерелүче), шулай ук яңа яшәү урынына үз ихтыярлары белән чыгып киткән гражданнарга яңа һөнәрләргә өйрәнү һәм эшкә урнашу чорына уртача хезмәт хакы саклау буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2012 елның 26 июлендәге 601 номерлы боерыгы (Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 26.10.2015 № 762, 07.06.2016 № 317, 08.06.2017 № 350, 30.11.2017 № 841, 15.05.2018 № 368, 18.09.2018 № 883, 20.06.2019 № 486, 03.09.2019 № 664, 12.11.2019 № 988 боерыклары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) белән расланган Чернобыль АЭСында һәлакәт, 1957 елда «Маяк» җитештерү берләшмәсендә авария һәм Тичә елгасына радиоактив калдыклар элгү аркасында радиактив пычрануның аерым зоналары территориясеннән эвакуацияләнгән күчерелгән (кучерелүче), шулай ук яңа яшәү урынына үз ихтыярлары белән чыгып киткән гражданнарга яңа һөнәрләргә өйрәнү һәм эшкә урнашу чорына уртача хезмәт хакы саклау буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентында (алга таба – Регламент):

2 бүлектә:

«Стандартка карата таләпләр эчтәлеге» графасында:

2.4 пунктның дүртенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Гариза бирүчегә уртача хезмәт хакын саклап калу (саклап калудан баш тарту) турында кабул ителгән карар турында хәбәр итү уртача хезмәт хакын саклап калу (саклап калудан баш тарту) турында карар кабул ителгән көннән соң бер эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.»;

2.5 пунктта:

беренче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. 1. Уртача хезмәт хакын саклап калу турында гариза (почта адресын яки гариза бирүче тарафыннан федераль законнар нигезендә социаль түләүләрне алу өчен кредит оешмасында ачылган счет реквизитларын күрсәтеп) (гариза формасы әлеге Регламентның 1 нче кушымтасында китерелгән).»;

дүртенче абзацны көчен югалткан дип танырга;

җиденче абзацта түбәндәге сүзләр өстәргә: «, хезмәт кенәгәсен яисә хезмәт эшчәнлеге турында мәгълүмат.»;

түбәндәге эчтәлекле абзацлар өстәргә:

«Хезмәт эшчәнлеге турында мәгълүмат гариза бирүче тарафыннан түбәндәгечә алынырга мөмкин:

тиешле рәвештә таныкланган кәгазь документ яисә көчәйтелгән квалификацияле электрон имза (эшкә бирүчедә булган очракта) белән имзаланган электрон документ формасында соңгы эш урыны буенча эш бирүчедән (әлеге эш бирүчедә эшләгән чор өчен);

дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәгендә тиешенчә расланган кәгазь документ рәвешендә;

Россия Федерациясе Пенсия фондыннан тиешле рәвештә расланган кәгазь документ рәвешендә яисә көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзаланган электрон документ формасында;

дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең бердәм порталыннан файдаланып, көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзаланган электрон документ рәвешендә.»;

Регламентка 1 нче кушымтада «киңәш ителәэ торган» сүзләрен төшереп калдырырга.

2. Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Радиация тәэсиренә бәйле рәвештә сәламәтлеккә китерелгән зыянны каплау өчен ай саен түләнә торган акчалата компенсация (сумма) билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2012 елның 26 июлендәге 602 номерлы боерыгы (Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 18.11.2015 № 850, 07.06.2016 № 317, 08.06.2017 № 350, 15.11.2017 № 802, 19.02.2018 №138, 15.05.2018 №368, 18.09.2018 №886, 20.06.2019 №486, 03.09.2019 №664, 12.11.2019 №988 боерыклары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) белән расланган Радиация тәэсиренә бәйле рәвештә сәламәтлеккә китерелгән зыянны каплау өчен ай саен түләнә торган акчалата компенсация (сумма) билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентында (алга таба – Регламент):

2 бүлектә:

«Стандартка карата таләпләр эчтәлеге» графасында:

2.4 пунктның дүртенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Компенсация билгеләү (билгеләүдән баш тарту) турында гариза бирүчегә хәбәр итү компенсация билгеләү (билгеләүдән баш тарту) турында карар кабул ителгән көннән соң бер эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.»;

2.5 пунктта:

беренче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Компенсация билгеләү турында гариза (почта адресын яки гариза бирүче тарафыннан федераль законнар нигезендә социаль түләүләрне алу өчен кредит оешмасында ачылган счет реквизитларын, гариза бирүче яшәгән урын буенча теркәлгән гражданнар турындагы белешмәләрне күрсәтеп) (гариза формасы әлеге Регламентның 1 нче кушымтасында китерелгән). Опекун (попечитель) гариза бирүчегә социаль түләүләрне күчерү өчен кредит оешмасында опекун (попечитель) тарафыннан ачтырылган номинал счет реквизитларын тапшыра.»;

дүртенче абзацны үз көчен югалткан дип танырга (әлеге абзац таләбе 2020 елның 1 июленнән гамәлдә);

алтынчы абзацта «хезмәт кенәгәсенең» сүзләрен «билгеләнгән тәртиптә расланган хезмәт кенәгәсенең күчермәсен һәм (яки) хезмәт эшчәнлеге турында белешмәләрне» сүзләренә алмаштырырга;

унынчы абзацта «хезмәт кенәгәсенең» сүзләрен «билгеләнгән тәртиптә расланган хезмәт кенәгәсенең күчермәсен һәм (яки) хезмәт эшчәнлеге турында белешмәләрне» сүзләренә алмаштырырга;

түбәндәге эчтәлекле абзацлар өстәргә:

«Хезмәт эшчәнлеге турында мәгълүмат гариза бирүче тарафыннан түбәндәгечә алынырга мөмкин:

тиешле рәвештә таныкланган кәгазь документ яисә көчәйтелгән квалификацияле электрон имза (эшкә бирүчедә булган очракта) белән имзаланган электрон документ формасында соңгы эш урыны буенча эш бирүчедән (әлеге эш бирүчедә эшләгән чор өчен);

дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәгендә тиешенчә расланган кәгазь документ рәвешендә;

Россия Федерациясе Пенсия фондыннан тиешле рәвештә расланган кәгазь документ рәвешендә яисә көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзаланган электрон документ формасында;

дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең бердәм порталыннан файдаланып, көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзаланган электрон документ рәвешендә.»;

2.6 пунктның җиденче абзацында «шәхси счет» сүзләреннән соң «, инвалидлык билгеләү факты турында» сүзләрен өстәргә (әлеге абзац таләбе 2020 елның 1 июленнән гамәлдә);

3 бүлектәге 3.4.2 пунктның җиденче абзацында «шәхси счет» сүзләреннән соң «, инвалидлык билгеләү факты турында» сүзләрен өстәргә (әлеге абзац таләбе 2020 елның 1 июленнән гамәлдә);

Регламентка 1 нче кушымтада «киңәш ителә торган» сүзләрен төшереп калдырырга.

3. Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Торак урынга һәм коммуналь хезмәтләргә түләүгә субсидия билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2014 елның 19 ноябрендәге 635 номерлы боерыгы (Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 07.06.2016 № 317, 31.10.2016 № 612, 08.06.2017 № 349, 01.06.2018 № 426, 18.09.2018 № 860, 23.04.2019 № 297, 14.11.2019 № 1021 боерыклары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) белән расланган Торак урынга һәм коммуналь хезмәтләргә түләүгә субсидия билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентында (алга таба – Регламент):

2 бүлектә:

«Стандартка карата таләпләр эчтәлеге» графасында:

2.4 пунктының өченче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Гражданин шәхсән мөрәҗәгать иткән очракта (гаризаны һәм документларны почта аша җибәргәндә) яки дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе гариза бирүченең Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталындагы

шәхси кабинетында урнаштырылган очракта, гариза бирүчегә субсидия бирү (субсидия бирүдән баш тарту) турында кабул ителгән карар хакында субсидия билгеләү (субсидия билгеләүдән баш тарту) турында карар кабул ителгәннән соң бер эш көне эчендәә хәбәр ителә.»;

2.5 пунктта:

беренче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Гаиләнең барлык әгъзаларын һәм туганлык дәрәҗәсен, почта адресын яки социаль түләүләрне алу өчен, федераль законнар нигезендә гариза бирүче тарафыннан кредит оешмасында ачылган счет реквизитларын күрсәтеп, гариза.

Гариза формасы әлеге Регламентның 1 нче кушымтасында китерелгән.

егерме тугызынчы абзацта «эштән китү турындагы соңгы язу белән хезмәт кенәгәсенең күчермәсе» сүзләрен «эштән китү турындагы соңгы язу белән билгеләнгән тәртиптә таныкланган хезмәт кенәгәсе күчермәсе һәм (яки) хезмәт эшчәнлеге турында мәгълүматлар» сүзләренә алмаштырырга;

түбәндәге эчтәлекле абзацлар өстәргә:

«Хезмәт эшчәнлеге турында мәгълүмат гариза бирүче тарафыннан түбәндәгечә алынырга мөмкин:

тиешле рәвештә таныкланган кәгазь документ яисә көчәйтелгән квалификацияле электрон имза (эш бирүчедә булган очракта) белән имзаланган электрон документ формасында соңгы эш урыны буенча эш бирүчедән (әлеге эш бирүчедә эшләгән чор өчен);

дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәгендә тиешенчә расланган кәгазь документ рәвешендә;

Россия Федерациясе Пенсия фондыннан тиешле рәвештә расланган кәгазь документ рәвешендә яисә көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзаланган электрон документ формасында;

дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең бердәм порталыннан файдаланып, көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзаланган электрон документ рәвешендә.»;

2.6 пунктның унөченче абзацында «Россия Федерациясе» сүзләреннән соң «, инвалидлык билгеләү факты турында» сүзләрен өстәргә (әлеге абзац таләбе 2020 елның 1 июленнән гамәлдә);

3 бүлектә:

3.3.2.1 пунктының бишенче абзацында «Россия Федерациясе» сүзләреннән соң «, инвалидлык билгеләү факты турында» сүзләрен өстәргә;

3.3.2.2 пунктының унынчы абзацында «Россия Федерациясе» сүзләреннән соң «, инвалидлык билгеләү факты турында» сүзләрен өстәргә;

3.4.2.1 пунктының бишенче абзацында «Россия Федерациясе» сүзләреннән соң «, инвалидлык билгеләү факты турында» сүзләрен өстәргә;

3.4.2.2 пунктының унынчы абзацында «Россия Федерациясе» сүзләреннән соң «, инвалидлык билгеләү факты турында» сүзләрен өстәргә;

(унсигезенче – егерме беренче абзацлар таләбе 2020 елның 1 июленнән гамәлдә була);

Регламентка 1 нче кушымтада «киңәш ителә торган» сүзләрен төшереп калдырырга.

4. Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Бөек Ватан сугышы ветераны» таныклыгын (таныклык дубликатын) бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2012 елның 05 июлендәге 514 номерлы боерыгы (Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 06.06.2014 № 309, 22.06.2015 № 425, 07.06.2016 № 317, 08.06.2017 № 350, 07.05.2018 № 347, 19.09.2018 № 892, 09.01.2019 № 8, 13.05.2019 № 362, 14.11.2019 № 1022 боерыклары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) белән расланган «Бөек Ватан сугышы ветераны» таныклыгын (таныклык дубликатын) бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентында (алга таба – Регламент):

2.6 пунктының «Стандартка карата таләпләр эчтәлеге» графасындагы беренче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Индивидуаль шәхси счетның иминият номеры турында белешмәләр, Бөек Ватан сугышы елларында телда хезмәт стажын билгеләү турында белешмәләр ведомствоара хезмәттәшлек каналлары аша алына – 1941 елның 22 июненнән 1945 елның 9 маена кадәр кимендә алты ай тылда эшләгән гражданнарга, гариза бирүчегә таныклык (таныклык дубликаты) бирү өчен (Россия Федерациясе Пенсия фондында).»;

Регламентка 1 нче кушымтада «Киңәш ителә торган» сүзләрен төшереп калдырырга.